| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.12.2021 г.Казань № 928

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2022 елның 17 гыйнварендә 8802 номеры белән теркәлде

Авыл җирендә яшәүче һәм озак вакытлы карау системасына кертелгән өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны Татарстан Республикасының көндез килеп тору бүлекчәләрендә (төркемнәрендә) социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына китерү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары Т.А.Голикованың 2021 елның 6 октябрендәге ТГ-П45-13962 номерлы йөкләмәсе нигезендә боерык бирәм:

1. Авыл җирендә яшәүче һәм озак вакытлы карау системасына кертелгән өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны Татарстан Республикасының көндез килеп тору бүлекчәләрендә (төркемнәрендә) социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына китерү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы карамагындагы көндез килеп тору бүлекчәләре (төркемнәр) ачылган социаль хезмәт күрсәтү оешмалары җитәкчеләренә югарыда күрсәтелгән Тәртип үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Ю.И.Абдреевага йөкләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.12.2021 № 928 боерыгы белән расланды

Авыл җирендә яшәүче һәм озак вакытлы карау системасына кертелгән өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны Татарстан Республикасының көндез килеп тору бүлекчәләрендә (төркемнәрендә) социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына китерү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Авыл җирендә яшәүче һәм озак вакытлы карау системасына кертелгән өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны Татарстан Республикасының көндез килеп тору бүлекчәләрендә (төркемнәрендә) социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына китерү тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары Т.А.Голикованың 2021 елның 6 октябрендәге ТГ-П45-13962 номерлы йөкләмәсе нигезендә эшләнде.

1.2. Тәртип авыл җирендә яшәүче һәм озак вакытлы карау системасына кертелгән өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны Татарстан Республикасының көндез килеп тору бүлекчәләрендә (төркемнәрендә) социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына (алга таба – социаль хезмәт күрсәтү оешмалары) китерүнең максатларын, кагыйдәләрен һәм шартларын билгели.

1.3. Тәртип Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына караган, Татарстан Республикасы муниципаль районнарында халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләрендә (алга таба – халыкка комплекслы хезмәт күрсәтү үзәкләре) үтәлергә тиеш.

## II. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына китерү максаты

2.1. Максаты булып авыл җирендә яшәүче һәм озак вакытлы карау системасына кертелгән өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны көндезге бүлекләрдә (төркемнәрдә) социаль хезмәт күрсәтү өчен, социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына китерү тора.

## III. Социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына китерү кагыйдәләре һәм шартлары

3.1. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына китерү халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм күрсәтү һәм аларның тормыш сыйфатын күтәрү программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру» федераль проекты кысаларында федераль бюджет акчалары хисабыннан сатып алынган автотранспорт чарасында гамәлгә ашырыла.

3.2. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына китерү өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны, алар яши торган торак йорттан алып социаль хезмәт күрсәтү оешмасына кадәр алып килүне һәм кире илтүне күздә тота.

3.3. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына китерү китерелергә тиешле өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар исемлеге (алга таба – Исемлек) һәм көндез килеп тору бүлекчәләрендә (төркемнәрендә) хезмәт күрсәтелә торган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны китерү графигы (алга таба – График) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Исемлек социаль хезмәт күрсәтү оешмасы (халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең көндез килеп тору бүлеге, көндезге килеп тору төркеме оештырылган халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлеге) тарафыннан әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтадагы форма буенча авыл җирлегендә яши торган өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның социаль хезмәт күрсәтү оешмасына илтү турында мохтаҗлык турында язмача белдерүләре (алга таба – Белдерү) нигезендә төзелә, белдерүләр алар (аларның законлы вәкилләре) тарафыннан алар белән көндез килеп тору бүлегендә (төркемендә) социаль хезмәтләр күрсәтү турында шартнамә төзегәндә тапшырыла.

Исемлек Белдерү кабул ителгән көннән башлап биш эш көне эчендә төзелә һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмасы (халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең көндез килеп тору бүлеге, көндезге килеп тору төркеме оештырылган халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлеге) тарафыннан халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенә (халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлегенә) атна саен җомга көннәрендә Мәскәү вакыты белән 12.00 сәгатькә кадәр кулга тапшырып яисә элемтәнең якланган каналлары буенча тапшырыла. Исемлек атна саен яңартылып тора.

Исемлек нигезендә халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре тарафыннан атна саен әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасына ярашлы формада График төзелә, ул, Исемлек алынган көннән алып ике эш көне дәвамында социаль хезмәт күрсәтү оешмасы директоры белән килештереп, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәге директоры тарафыннан раслана.

Социаль хезмәт күрсәтү оешмасына илтелергә тиешле өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга График төзелгән көннән соң ике эш көне эчендә социаль хезмәт күрсәтү оешмасы тарафыннан Белдерүдә күрсәтелгән ысул белән халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмасына китерү һәм кире илтү көннәре, вакыты, шул исәптән автотранспортка утырту урыны турында да, мәгълүмат җиткерелә.

3.4. Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны социаль хезмәт күрсәтү оешмасына китерү халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең озата йөрүче хезмәткәре (бер автотранспортка бер озата йөрүче) тарафыннан башкарыла.

3.5. Өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар социаль хезмәт күрсәтү оешмасына әлеге Тәртипкә туры китереп, түләүсез нигездә китереләләр.

## IV. Илтеп җиткерүдә катнашучылар һәм аларның бурычлары

4.1. Илтеп җиткерүдә катнашучылар булып халыкка комплекслы социаль

хезмәт күрсәтү үзәге һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмасы тора.

4.2. Халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәге түбәндәгеләрне тәэмин итә:

социаль хезмәт күрсәтү оешмасына өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны китерүне планлаштыра һәм контрольдә тота;

өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны йөртү өчен, кирәк булган очракта, хәрәкәт итүдә шактый чикләмәләре булган, шул исәптән коляска-креслода йөри торган инвалидлар өчен автотранспортны кресло-коляска белән җиһазландыра;

автотранспортның алгы панелендә (машина йөртүчедән уң якта) түбәндәге мәгълүматны урнаштыра: халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең тулы исеме, адресы, белешмә телефоннары; йөртүченең фотолы визит карточкасы; транспорт хезмәте күрсәтүне контрольдә тотуны тәэмин итүче органның атамасы, адресы һәм белешмә телефоннары.;

автотранспортның техник торышы, эшне башлау һәм тәмамлау вакыты турында, спидометр күрсәткечләре белән көн саен исәпкә алу журналын алып бару;

социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының көндез килеп тору бүлекчәләренә (төркемнәренә) китерелгән өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны көндәлек исәпкә алу;

социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының көндезге тору бүлекчәләренә (төркемнәренә) китерелгән өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар саны турында хисап аеннан соңгы айның 5 нче көненә кадәр Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына ай саен хисаплылык тапшыра.

4.3. Халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәге машина йөртүчесе:

куркынычсыз урында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны утыртуны тәэмин итә;

өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга, шул исәптән кресло-коляскада хәрәкәт итүче, автотранспортка утырганда һәм төшкәндә ярдәм күрсәтә;

өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны куркынычсызлык каешлары белән эләктерә;

автотранспортта кресло-коляска ныгыта.

4.4. Халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең озата йөрүче хезмәткәре (социаль хезмәткәр, социаль эш буенча белгеч) түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга автотранспортка кадәр хәрәкәт иткәндә, ә социаль хезмәт күрсәтү оешмасыннан кайтканда - яшәү урынына кадәр хәрәкәт иткәндә ярдәм күрсәтә;

социаль хезмәт күрсәтү оешмасына кадәр китереп җиткерү һәм кире кайтару вакытында озатып йөри;

өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга, аларны социаль хезмәт күрсәтү оешмасына илткән вакытта сәламәтлеге начарайган очракта, ашыгыч медицина ярдәмен чакырта.

4.5. Социаль хезмәт күрсәтү оешмасы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга көндез килеп тору бүлекчәләренә (төркемнәргә) китерү датасы һәм вакыты турында Белдерүдә күрсәтелгән ысул белән хәбәр итә;

өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның законлы вәкилләрен көндезге бүлекләргә (төркемнәргә) китерү графигы белән язмача таныштыра;

өлкән яшьтәге гражданнарны, инвалидларны социаль хезмәт күрсәтү оешмасына керү юлында каршы ала һәм көндезге бүлекләргә (төркемнәргә) озатып куя;

шөгыльләрдән соң халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәге автотранспортына кадәр баруда, автотранспортка утыртуда ярдәм итә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.12.2021 № 928 карарына 1 нче кушымта

форма

Көндез килеп тору бүлекчәләренә (төркемнәренә) китерелергә тиешле өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар исемлеге

______________________________________________

*социаль хезмәт күрсәтү оешмасының исеме*

202___ елның «___» _______ башлап «____»______кадәр

| Социаль хезмәтләрдән файдаланучы затның ФИА | Социаль хезмәтләрдән файдаланучының яшәү адресы | Социаль хезмәтләрдән файдаланучының (аның законлы вәкиленең) элемтә белешмәләре | Көндез килеп тору бүлегенә (төркеменә) килү көне | Социаль хезмәтне күрсәтә башлау һәм тәмамлау вакыты |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Социаль хезмәт күрсәтү
оешмасы директоры ___________________ _________________________

*имза* *ФИА*

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.12.2021 № 928 карарына 2 нче кушымта

форма

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ:
Социаль хезмәт күрсәтү оешмасы директоры

______________________________
Фамилия, исем, ата исеме
______________________________
(имза)
«________»__________20_____ел

РАСЛАНДЫ:
Халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәге директоры

______________________________
Фамилия, исем, ата исеме
______________________________
(имза)
«________»__________20_____ел

Көндез килеп тору бүлекчәләрендә (төркемнәрендә) хезмәт күрсәтелә торган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны китерү графигы

______________________________
*социаль хезмәт күрсәтү оешмасының исеме*
202___ елның «___» _______ башлап «____»______кадәр

| Китерү көне | Китерелә торган гражданинны (алга таба – гражданин) яшәү урыныннан автотранспортка утырту вакыты | Гражданинны социаль хезмәт күрсәтү оешмасына китерү вакыты | Гражданин яши торган торак пункт исеме | Гражданинның адресы | Китерелергә тиешле гражданинның ФИА | Гражданинның (аның законлы вәкиленең) элемтә белешмәләре | Гражданинны социаль хезмәт күрсәтү оешмасы янында автотранспортка утырту вакыты | Яшәү урыны буенча гражданинны илтеп җиткерү вакыты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |